ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.01.2026 Балык Бистәсе штп. № 12 пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында" 17.08.2024 №234пи карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәй тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 30.03.2018 ел, №195, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 06.09.2025 №669, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмаган бюджет даирәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 25.11.2025 ел, №996» карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында" 17.08.2024 №234пи карарына ( 05.02.2025 №31пи; 17.06.2025 №145пи редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1) 1 пунктның 4 абзацында «15 389» санын «16 928» санына алмаштырырга;

1.2) 5 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“аерым оешмаларның җиңел автомобильләре йөртүчеләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә, ул тәшкил итә:

1) 4 разрядлы машина йөртүчеләр өчен-26540,0 сум;

2) 5 разрядлы машина йөртүчеләр өчен – 26871,0 сум”;

1.3) “Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Балык Бистәсе муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары” 1 кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә;

1.4) “Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Балык Бистәсе муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары” 2 кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы
Башкарма
комитетының 19.01.2026
№12пи карарына 1нче
кушымта

Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Балык Бистәсе муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары

| Вазифаның атамасы | Айлык вазыйфаи окладлар, сум |
|---|---|
| | V<br>группа |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе | 22684 |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе урынбасары | 22007 |
| Бүлек башлыгы | 21160 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 19806 |
| Баш белгеч | 18621 |
| Әйдәүче белгеч | 17775 |
| I категорияле белгеч | 16928 |
| II категорияле белгеч | 16928 |
| Белгеч | 16928 |

Искәрмә:
V төркем - Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Зәй, Лениногорск, Нурлат, Чистай шәһәрләре һәм I-IV төркемнәргә кертелмәгән Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы
Башкарма
комитетының 19.01.2026
№12пи карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Балык Бистәсе муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары

| Вазифаларның атамалары | Айлык вазыйфаи окладлар, сум |
| --- | --- |
| Архив мөдире, өлкән инспектор, машинкада язу, күчерү-күбәйтү бюросы мөдирләре, инспектор, статистик, хуҗалык, склад мөдирләре; кассир, комендант, эш башкаручы, архивариус, стенографистка, секретарь-стенографистка, машинистка, экспедитор, секретарь-машинистка, җитәкченең сәркатибе | 16 928 |